ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

13.11.2024 № 1029

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү тәртибен раслау турында» 2023 елның 18 июлендәге 933 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставының 80 статьясындагы 8 пункты, Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәнең 17 статьясы нигезендә (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү тәртибен раслау турында» 2023 елның 18 июлендәге 933 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. «Муниципаль район бюджеты проектын төзегәндә, түбәндәгеләр раслана дип билгеләргә:

а) Тәртипнең 5 пунктында каралган график «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан, районның Башкарма комитеты белән килештереп, 1 июльдән дә соңга калмыйча раслана;

б) Биектау муниципаль районының бюджет ассигнованиеләрен бүлү, чыгым йөкләмәләре күләме һәм структурасы, Тәртипнең 3 пунктындагы "б" һәм "г" пунктчаларында, 8 пунктында, 12 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында каралган бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләмнәрен проектлаштырулар буенча тиешле тәкъдимнәр чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты чараларын төп бүлүчеләр һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан формалаштырыла».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин